| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Подлесный **КАРАР**

№ 15 2019 елның 7 мае

«Реконструкция системы ППД.КНС-38 НГДУ «Лениногорскнефть» линияле объектларын төзү өчен территорияне планлаштыру проектын һәм аның составындагы территорияне межалау проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәр итү турында

Халыкның муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын, кеше яшәешенең уңай шартларын, җир участоклары хуҗаларының хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатыннан чыгып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 нче статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1., 46 нчы статьясы, «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Писмән авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан, “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 30 апрелендәге 586нчы номерлы Карары нигезендә әзерләнгән «Реконструкция системы ППД.КНС-38 НГДУ «Лениногорскнефть» линияле объектларын төзү өчен территорияне планлаштыру проектын һәм аның составындагы территорияне межалау проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү башлану турында хәбәр итәргә.

2. 2019 елның 14 маеннан 14 июненә кадәр аның составындагы территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау Проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрергә.

3. 2019 елның 14 маенда территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау Проектын “Писмән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Писмән авыл җирлеге, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 нче йорт адресы буенча авыл җирлеге бинасында, ТР Лениногорск муниципаль районы, Иске Писмән авылы, Центральная, 50нче йорт, мәдәният йорты бинасы адреслары буенча Экспозиция ачарга. Проект экспозициясе белән танышу вакытын 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр, дүшәмбе-җомга көннәрендә дип билгеләргә.

“Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге экспозициясе барышында экспозициягә килүчеләргә җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект турында консультация бирүне оештырырга.

4. 2019 елның 14 маена кадәр планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын рәсми сайтта «Шәһәр төзелеше, планлаштыру проектлары» бүлегендә түбәндәге адрес буенча: http://Leninogorsk.tatar.ru урнаштырырга.

5. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга планлаштыру проектына һәм аның составындагы межалау проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 нче йорт адресы буенча «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы исеменә язма рәвештә кертергә тәкъдим итәргә, электрон рәвештә түбәндәге адрес буенча: Pism.Len@tatar.ru, 2019 елның 14 маеннан 14 июненә кадәрге чорда

яисә халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын уздыру барышында телдән.

6. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышын Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында 15.00 сәгатькә билгеләргә.

7. Җәмәгать тыңлаулары башлану турында әлеге хәбәрне Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://Leninogorsk.tatar.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 нче йорт (административ бина), Подлесный бистәсе, Гагарин урамы, 1б (мәдәният йорты), Иске Писмән авылы, Центральная урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты), Дала Зәе поселогы, Дала Зәе урамы, 23 нче йорт, 1нче корылма (кибет), Воздвиженка поселогы, Түбән ур., 10 йорт (авыл клубы) адресы буенча мәгълүмат стендларында, «Лениногорские вести» газетында, шулай ук Дурасово авылы, Югары Каран авылы, Савочкино авылы, Восход авылы торак пунктларында 2019 елның 14 маена кадәр белдерүләр элеп куярга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

«Писмән авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлеге Башлыгы Р.В.Насретдинов